# Таныш булыйк – бу мин!

**Муллина Диана**



# Үзем турында

Минем исемем Муллина Диана Илнар кызы.

Мин 2004нче елның 18нче ноябрендә Түбән Кама шәһәрендә туганмын.







# Мин нинди кыз?

Мин – яхшы күңелле, юмарт, кызык, акыллы, тәртипле, тәрбияле кыз.

Мин  кайвакыт хәйләкәр була алам, кайвакыт ялкауланам.

Мин матур, сөйкемле, уртача буйлы, озын һәм калын чәчле, көрән күзле кыз.

Мин барлык кешеләрне кызганам, дусларыма ярдәм итәргә һәрвакыт әзер.

Миңа усал, начар, саран кешеләр ошамый, бары тик яхшы, тыныч кешеләр генә ошый.





# Минем яраткан гаиләм



Минем әнием, Муллина Айгөл Рөстәм кызы, 33 нче мәктәптә укытучы булып эшли. Минем әни акыллы, чибәр, уңган хатын-кыз һәм яхшы укытучы. Аны укучылары бик яраталар!




Әтием, Муллин Илнар Миредиян улы, Түбән Кама шин заводында җиһазлар көйләүче булып эшли. Әтием көчле, тырыш, эшендә алыштыргысыз, абруйлы мастер!




Абыем, Муллин Динар Илнар улы 32нче гимназиянең 9нчы А сыйныфында укый. Ул спорт белән шөгыльләнә, яхшы укый.


Абыем белән бик горурланам!

# Минем исемем

Диана исеме борынгы Рим вакытларыннан ук билгеле. Аның тәрҗемәсе – илаһи (божественная).

Римлылар Диана алиһәсен Ай белән чагыштырганнар, ә ул ау химаячесе булган (покровительница охоты)

Борынгы фарсы телендә Диана исеме “сәламәтлек һәм игелек илчесе” дигәнне аңлата (посланник здоровья и благодеяния)




# Мин нәрсәләр белән шөгыльләнәм

Мин И.Х. Садыков исемендәге балалар һәм яшьләр иҗаты сараена әдәби түгәрәккә һәм спорт – бал бию түгәрәгенә йөрим.

Буш вакытларымда оригами, рәсем ясарга, тегәргә, салатлар ясарга, төрле экспериментлар ясарга, биергә, җырларга, совет киноларын карарга яратам.





# Киләчәктә кем булырга телим.



Минем хыялым - ветеринар булу!

Мин барлык җәнлекләрне яратам, кызганам, аларга ярдәм итәргә телим. Урамда йөргән песиләр, этләр яныннан битараф үтеп китә алмыйм, ашатам.

Барлык хуҗасыз калган хайваннарны үземә алыр идем!

Ветеринар булу өчен миңа бигрәк тә биология фәнен тырышып өйрәнергә кирәк!



Игътибарыгыз өчен рәхмәт!

